| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЗЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЗЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.08.2025 с. Азево № 11

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге башкарма комитетының 03.09 2021 елда кабул иткән 15нче номерлы «Агачларны, куакларны газонны кисү, формалаштыру һәм күчереп утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 03 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге территориясендәге Россия Федерациясе дәүләти урман фондына һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында”гы 2021 елның 12 февралендә кабул ителгән 7-1 номерлы карарын исәпкә алып, Әгерҗе районы прокуратурасының 11.03.2025-02-08-01-2025/Прдп97-25-20920003/41 номерлы карарына , ..... Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Азево авыл җирлеге башкарма комитеты карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге башкарма комитетының «Агачларны, куакларны, газонны формалаштыруга, сүтүгә һәм күчереп утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 03.09.2021 кабул ителгән 15нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.5.2.1 пунктының 7 абзацын, 3.5.2.2 пунктының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге территориясендә киселә торган яшел үсентеләрнең һәм компенсацион яшелләндерү бәясен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге башкарма комитетының 25.08.2025 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге

территориясендә кiселә торган яшел үсентеләрнең бәясен исәпләү методикасы нигезендә исәпләп чыгара”

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында бастырырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составында Әгерҗе муниципаль районының официаль сайтында https://agryz.tatarstan.ru веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәренә урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Азево авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкчесе В.С.Семенов